КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1007

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана торган Дару чаралары белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы гражданнарга реализацияләнә торган дару чаралары һәм медицина әһәмиятендәге әйберләр исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карары белән расланган Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана торган Дару чаралары белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы гражданнарга реализацияләнә торган дару чаралары һәм медицина әһәмиятендәге әйберләр исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 16 март, 149 нчы; 2011 ел, 28 апрель, 343 нче; 2017 ел,

15 ноябрь, 879 нчы; 2018 ел, 28 май, 405 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлегенә, «Миокард инфаркты (беренче алты ай)» юлында «беренче алты ай» сүзләрен «беренче унике ай» сүзләренә алыштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин